# Сүзлек өстендә эш

- **карлыгач-ласточка**
- **алабуга-окунь**
- **бүдәнә-перепелка**

*"Адашкан авазлар" С.Вәгыйзов*

**Ничек булса да булган: авазлар юлдан язган.**
**Чит сүзләргә кергәннәр һәм адашып йөргәннәр.**
**Карлыгач пешеп утырган су буенда куакта,**
**Ә карлыган очып йөргән зәңгәр күктә — еракта.**
**Чиста күлмәген киеп, бака мәктәпкә килгән.**
**Балалы сазга төшкән озын ботлы бер челән.**
**Күктә базлар очканнар, җирдә каз казыганнар.**
**Симергәннәр диңгезләр, дулкынланган дуңгызлар.**
**Касмакка җим каптырып, алабута тотканнар.**
**Балыкларын майга салып, кабада кыздырганнар.**
**Фермадагы тавыклар салганнар, ди, йомычка,**
**Кертеп мичкә якканнар кочак-кочак йомырка.**
**Шундый кызык икән монда: бронзаны ашыйлар.**
**Брынзаны утта эретеп, төрле әйбер ясыйлар.**
**Игеннәр өлгергән чакта, шундый хәлләр була, ди:**
**Бүрәнәләр, очып килеп, бүдәнәгә куна, ди.**
**Мондый хәлләрне күргәч, авазлар "аһ!" иткәннәр**
**һәм бергә ант иткәннәр - читкә борын тыкмаска,**
**үз сүзеңнән чыкмаска.**

**А...а кү...еле балада шул,**
**Бала кү...еле далада.**
**Го…еркәйләр үтеп киткән,**
**Сизел...и кай арада.**

Э.Мөэминова

-  Ана күңеле балада шул,
-  Бала күңеле далада.
-  Гомеркәйләр үтеп киткән,
-  Сизелми кай арада.

# М,н,ң тартыклары

**Малай, кием, күлмәк, имән.**

[М] – ирен-ирен тартыгы

**Куян, тиен, каен, нарат.**

[Н] – тел-теш тартыгы

**Яңгыр, таң, бәрәңге, чаңгы.**

[ң] – кече тел тартыгы

Зә…гәр,  …атур, та…чы, шу…а, ка…ат, ...
арат, и…тиха…, …иһерба..лы, ки…, тә…ле,
ки…лек, …иләш,.а…лы, озакла…ый, ту…а,
беле…ле, кү…ел, бәрә…ге, бәйрә… .

Яңгыр, яңгыр, ни өчен
Җирнең битен юасың?
Җирнең битен юа, юа
Агартмакчы буласың?

Яңгыр ,яу, яу, яу!
Илдә уңыш мул булсын,
Үләннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын,
Безгә эчәргә сөт булсын.

